МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РОССИЙСКОЙ ФЕДЕРАЦИИ
Федеральное государственное автономное учреждение
высшего профессионального образования
"Казанский (Приволжский) федеральный университет"
Отделение массовых коммуникаций

**УТВЕРЖДАЮ**
Проректор
по образовательной деятельности КФУ
Проф. Минзарипов Р.Г.

*подписано электронно-цифровой подписью*

# Программа дисциплины

История татарской литературы XX века Б3.ДВ.5

Направление подготовки: 031300.62 - Журналистика
Профиль подготовки: Средства массовой информации (национальная журналистика)
Квалификация выпускника: бакалавр
Форма обучения: очное
Язык обучения: русский

**Автор(ы):**
Фаттахов И.Ф.
**Рецензент(ы):**
Гарифуллин В.З. , Зайни Р.Л.

**СОГЛАСОВАНО:**
Заведующий(ая) кафедрой: Гарифуллин В. З.
Протокол заседания кафедры No ___ от "____" ___________ 201__г
Учебно-методическая комиссия Института социально-философских наук и массовых коммуникаций (отделение массовых коммуникаций):
Протокол заседания УМК No ____ от "____" ___________ 201__г

Регистрационный No 941891314

Казань
2014


ЭЛЕКТРОННЫЙ УНИВЕРСИТЕТ
ИНФОРМАЦИОННО-АНАЛИТИЧЕСКАЯ СИСТЕМА КФУ

## Содержание

1. Цели освоения дисциплины
2. Место дисциплины в структуре основной образовательной программы
3. Компетенции обучающегося, формируемые в результате освоения дисциплины /модуля
4. Структура и содержание дисциплины/ модуля
5. Образовательные технологии, включая интерактивные формы обучения
6. Оценочные средства для текущего контроля успеваемости, промежуточной аттестации по итогам освоения дисциплины и учебно-методическое обеспечение самостоятельной работы студентов
7. Литература
8. Интернет-ресурсы
9. Материально-техническое обеспечение дисциплины/модуля согласно утвержденному учебному плану


ЭЛЕКТРОННЫЙ УНИВЕРСИТЕТ
ИНФОРМАЦИОННО-АНАЛИТИЧЕСКАЯ СИСТЕМА КФУ

Программу дисциплины разработал(а)(и) доцент, к.н. Фаттахов И.Ф. Кафедра татарской журналистики Отделение массовых коммуникаций , Ilgam.Fattahov@kpfu.ru

## 1. Цели освоения дисциплины

Выявление и осмысление закономерностей и ведущих тенденций развития татарской литературы послеоктябрьского периода ХХ века и начала ХХ1 века в ее основных художественных достижениях и противоречиях; изучение творчества крупнейших писателей в контексте определенного литературного периода.

## 2. Место дисциплины в структуре основной образовательной программы высшего профессионального образования

Данная учебная дисциплина включена в раздел " Б3.ДВ.5 Профессиональный" основной образовательной программы 031300.62 Журналистика и относится к дисциплинам по выбору. Осваивается на 4 курсе, 7 семестр.

Данная учебная дисциплина входит в раздел "Б.3.Д.В5. Профессиональный цикл. Базовая часть" ФГОС-3 по направлению подготовки ВПО 032700- "Журналистика".

## 3. Компетенции обучающегося, формируемые в результате освоения дисциплины /модуля

В результате освоения дисциплины формируются следующие компетенции:

| Шифр компетенции | Расшифровка приобретаемой компетенции |
|---|---|
| ОК-10 (общекультурные компетенции) | способность к социальной и профессиональной адаптации, социальной и профессиональной мобильности (ОК-10); |
| ОК-15 (общекультурные компетенции) | способность использовать знания в области естественнонаучных дисциплин, базироваться на принципах научного подхода в процессе формирования своих мировоззренческих взглядов, касающихся взаимоотношений человека с окружающей средой и проблем безопасности жизнедеятельности и умение использовать естественнонаучные знания в своей социальной и профессиональной деятельности (ОК-15); |
| ПК-38 (профессиональные компетенции) | знание основ организации научного исследования в сфере журналистики (ПК-38); |
| ПК-54 (профессиональные компетенции) | участвовать в организации ?внетекстовых? редакционных акций, социальных проектов (общественно-политических, экологических, благотворительных, развлекательных) в разных формах (ПК-54); |
| ПК-56 (профессиональные компетенции) | участвовать в обеспечении общественного резонанса публикаций, передач (ПК-56); |
| ОК-1 (общекультурные компетенции) | готовность уважительно и бережно относиться к историческому наследию и культурным традициям, толерантно воспринимать социальные и культурные различия, руководствоваться ими в профессиональной деятельности (ОК-1); |



ЭЛЕКТРОННЫЙ УНИВЕРСИТЕТ
ИНФОРМАЦИОННО-АНАЛИТИЧЕСКАЯ СИСТЕМА КФУ

| Шифр компетенции | Расшифровка приобретаемой компетенции |
|---|---|
| ПК-1 (профессиональные компетенции) | способность демонстрировать знание основных положений и концепций в области теории и истории татарской литературы, филологического анализа и интерпретации текста, представление об истории, современном состоянии и перспективах развития филологии |
| ПК-5 (профессиональные компетенции) | способность применять полученные знания в области теории и истории основногоизучаемого языка (языков) и литературы (литератур), теории коммуникации, филологического анализа и интерпретации текста в собственной научно-исследовательской деятельности |
| ПК-55 (профессиональные компетенции) | организовывать интерактивное общение со своей аудиторией в разных формах, устанавливать коммуникативно-информационные связи, используя различные медийные средства и новейшие технологии (ПК-55); |
| ПК-7 (профессиональные компетенции) | владение навыками подготовки научных обзоров, аннотаций, составления рефератов и библиографий по тематике проводимых исследований, приемами библиографического описания; знание основных библиографических источников и поисковых систем (ПК-7); |
| ПК-8 (профессиональные компетенции) | владение навыками участия в научных дискуссиях, выступления с сообщениями и докладами, устного, письменного и виртуального (размещение в информационных сетях) представления материалов собственных исследований |

В результате освоения дисциплины студент:

1. должен знать:

общественно-культурные условия, под влиянием которых развивалась литература ХХ века; основных тенденций литературного процесса, тематическое разнообразие, богатства художественных средств, а также традиции и новаторства отдельных авторов и их литературно-эстетические искания.

2. должен уметь:

применять полученные знания в области теории и истории литературы, литературной критики.

3. должен владеть:

основными методами и приемами исследовательской и практической работы в области истории татарского литературы; навыками анализа и интерпретации прозаических, поэтических, драматических произведений на основе современных методик, а также самостоятельного изучения научно-критической литературы.

4. должен демонстрировать способность и готовность:

- способность к проведению учебных занятий и внеклассной работы по языку и литературе в общеобразовательных учреждениях и образовательных учреждениях среднего профессионального образования;

- умение организовать самостоятельный профессиональный трудовой процесс; владение навыками работы в профессиональных коллективах; способность обеспечивать работу данных коллективов соответствующими материалами про всех вышеперечисленных видах профессиональной деятельности;

## 4. Структура и содержание дисциплины/ модуля



ЭЛЕКТРОННЫЙ УНИВЕРСИТЕТ
ИНФОРМАЦИОННО-АНАЛИТИЧЕСКАЯ СИСТЕМА КФУ

Общая трудоемкость дисциплины составляет 4 зачетных(ые) единиц(ы) 144 часа(ов).

Форма промежуточного контроля дисциплины экзамен в 7 семестре.

Суммарно по дисциплине можно получить 100 баллов, из них текущая работа оценивается в 50 баллов, итоговая форма контроля - в 50 баллов. Минимальное количество для допуска к зачету 28 баллов.

86 баллов и более - "отлично" (отл.);

71-85 баллов - "хорошо" (хор.);

55-70 баллов - "удовлетворительно" (удов.);

54 балла и менее - "неудовлетворительно" (неуд.).

### 4.1 Структура и содержание аудиторной работы по дисциплине/ модулю

### Тематический план дисциплины/модуля

| N | Раздел Дисциплины/ Модуля | Семестр | Неделя семестра | Виды и часы аудиторной работы, их трудоемкость (в часах) | | | Текущие формы контроля |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Лекции | Практические занятия | Лабораторные работы | |
| 1. | Тема 1. : Иҗтимагый-сәяси атмосфера һәм мәдәни хәл. Әдәби юнәлеш, стиль һәм агымнар төрлелеге. XX гасыр башында татар прозасының яңарышы | 7 | 1-3 | 2 | 0 | 2 | контрольная работа |
| 2. | Тема 2. XX йөз башы татар шигърияте үсеше: мотивлар һәм жанрлар төрлелеге | 7 | 4-7 | 4 | 0 | 4 | тестирование |
| 3. | Тема 3. Милли драматургиянең үсеш баскычлары һәм аларның төп сыйфатлары | 7 | 8-9 | 2 | 0 | 2 | коллоквиум |
| 4. | Тема 4. Литература 1920-30-х годов (1917-1941) Литература в послевонные годы (1945-1960) | 7 | 10-11 | 2 | 0 | 2 | контрольная работа |
| 5. | Тема 5. Литература в послевонные годы (1945-1960) Литература в 1960-1985-е годы | 7 | 12-16 | 4 | 0 | 4 | творческое задание |
| 6. | Тема 6. Современная татарская литература (конец XX ? нач.XX1 вв.) | 7 | 17-18 | 4 | 0 | 4 | письменная работа |
| . | Тема . Итоговая форма контроля | 7 | | 0 | 0 | 0 | экзамен |


ЭЛЕКТРОННЫЙ УНИВЕРСИТЕТ
ИНФОРМАЦИОННО-АНАЛИТИЧЕСКАЯ СИСТЕМА КФУ

| N | Раздел Дисциплины/ Модуля | Семестр | Неделя семестра | Виды и часы аудиторной работы, их трудоемкость (в часах) | | | Текущие формы контроля |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Лекции | Практические занятия | Лабораторные работы | |
| | Итого | | | 18 | 0 | 18 | |

### 4.2 Содержание дисциплины

**Тема 1. : Иҗтимагый-сәяси атмосфера һәм мәдәни хәл. Әдәби юнәлеш, стиль һәм агымнар төрлелеге. XX гасыр башында татар прозасының яңарышы**

***лекционное занятие (2 часа(ов)):***

Милли профессиональ театр барлыкка килү һәм татар драматургиясенең яңа баскычка күтәрелүе, бу уңайдан рус һәм гареб драматурглары иҗатына мөрәҗәгать итү, тәрҗемә әсәрләренең драматургия үсешенә йогынтысы.1905-1907 елгы инкыйлаб казанышы буларак, сүз, матбугат ирееге игълан ителү. Әдәбият белеме фәненең бер тармагы буларак әдәби тәнкыйтьнең формалашуы.Милли профессиональ театр барлыкка килү һәм татар драматургиясенең яңа баскычка күтәрелүе. XX йөз башында яңа татар прозасының тәмам формалашып җитүе. Әдәбият галимнәре тарафыннан аның ике үсеш баскычы аерылып чыгарылу: 1. 1885-1908 еллар. 2. Унынчы еллар прозасы. . Әдәби мәйданга гасыр башында килеп кергән М.Гафуриның әсәрләрендә гади халык вәкилләренең авыр тормышы сурәтләнү, әдәбиятта гади кеше, аның бәхете мәсьәләсе куелу. Г.Исхакый прозасының милли сүз сәнгатенә яңа сулыш өрүе. Аның хикәя, повесть, романнарында татар прозасы үсешендә яңа төсмер, тенденцияләр күзәтелү.

***лабораторная работа (2 часа(ов)):***

Иҗат эшенә Беренче рус инкыйлабыннан соң килгән Г.Ибраһимов, Ф.Әмирхан, Ш.Камал, әдәби осталыклары яңа баскычка күтәрелгән Г.Исхакый, М.Гафуриларның хикәя-повестьларында татар прозасының яңа сыйфат үзгәрешләре чагылу.

**Тема 2. XX йөз башы татар шигърияте үсеше: мотивлар һәм жанрлар төрлелеге**

***лекционное занятие (4 часа(ов)):***

Татар шигъриятенең күпгасырлык тарихы, традицияләре. М.Гафуриның (1880-1934) башлангыч чор иҗатында мәгърифәткә, шәхес, акыл уянуына дан җырлану. 1905 нче ел инкыйлабының татар поэзиясен активлаштырып җибәрүе, шигърияткә көчле бер ташкын булып Г.Тукай (1886-1913), Н.Думави (1883-1933), М.Укмаси (1884-1946), З.Бәшири (1888-1962) кебек шагыйрьләрьнең килеп керүе. Милли поэзиянең демократик идеяләр белән сугарылуы, үзәктә хөррият, шәхес ирееге, социаль, милли, ил, халык азатлыгы идеяләре яту. Г.Тукайның ?Хөррият хакында? (1905), ?Дусларга бер сүз? (1905), М.Гафуриның ?Шатлык шигыре? (1905), ?Алмашыну? (1905) һ.б.ларның әсәрләрендә инкыйлабка ышаныч, өмет чагылу. Татар милләтенең мәдәни, рухи артталыгына, наданлыгына, ялкаулыгына, таркаулыгына борчылу, кайгыру, бу хәлдән чыгу юллары турында шагыйрьләрнең уйланулары, гамьнәре чагылу. Инкыйлаб чоры поэзиясенең диңгез, җил, давыл, таң, кояш кебек символик образларга мөрәҗәгать итүе, аңа публицистик аһәң, риторика хас булу..Тукайда сатирик, М.Гафурида сәяси лириканың калкулануы (Г.Тукай ?Государственная думага? (1906), ?Сорыкортларга? (1906), ?Безне урынсыз яманлыйлар? (1907); М.Гафури ?1906 елдан 1907 елга васыять? (1906), ?1907 елның җавабы? (1907); Н.Думави ?Эч поша, күңел болгана? (1906), ?Җәй үтеп, кышның башы җиткән иде? (1906); С.Рәмиев ?Таң ата эшлик, туганнар? (1906), ?Татарча Марсельеза? (1906) һ.б.). XX йөз башы татар поэзиясенең иҗтимагый-сәяси вакыйгаларга, тарихи фактларга, заман рухына үз мөнәсәбәтен тиз, ачык һәм кискен белдерүе. 1908-1910 еллар шигъриятендәге сыйфат үзгәрешләре. Аның сәбәпләре.Милли поэзиянең тәнкыйди реализм принципларын үзләштерү белән бергә романтик сурәтләү алымнары, чараларына мөрәҗәгать итүе. С.Рәмиев, Дәрдемәнд, Ш.Бабичларның шигърияткә яңа сулыш өрүе.

***лабораторная работа (4 часа(ов)):***



ЭЛЕКТРОННЫЙ УНИВЕРСИТЕТ ИНФОРМАЦИОННО-АНАЛИТИЧЕСКАЯ СИСТЕМА КФУ

10 елларда татар поэзиясенә шагыйрьләрнең икенче буыны килү: С.Сүнчәләй (1889-1941), З.Ярмәки (1887-1965), Г.Харис (1893-1931), Г.Сөнгати (1893-1917), М.Фәйзи (1891-1928), Ф.Бурнаш (1898-1946), Н.Исәнбәт (1899-1993), Г.Сәмитова (1862-1929), М.Мозаффария (1873-1945), М.Вәлидия (1894-1925), З.Бурнашева (1895-1977), Х.Шаммасова (1875-1949), З.Сәгыйдә (1897-? ) һ.б. Иҗади мөмкинлекләре, талантлары төрле дәрәҗәдә булуга карамастан, унынчы еллардагы милли шигъриятнең эчтәлеген һәм юнәлешен билгеләү ноктасыннан ул шагыйрьләрнең үз урыннары, үз рольләре булу.

**Тема 3. Милли драматургиянең үсеш баскычлары һәм аларның төп сыйфатлары**

***лекционное занятие (2 часа(ов)):***

XX йөз башы татар драматургиясе тарихын чорларга бүлү мәсьәләсе. Беренче чорның 1887-1905 елларга туры килүе. Г.Ильяси, Ф.Халиди, Г.Камал, Г.Исхакый, Я.Вәли һ.б. лар иҗаты. тәрҗемә әсәрләр барлыкка килү белән аңлатылуы. 1906 елда татар драматургиясе тарихында икенче чор башлану. Аның 1906-1911 еллар аралыгына туры килүе. Бу чорда аның яңа күтәрелеше. Тарихи-мәдәни сәбәпләре. Татар драматургиясенең ?театрлы? дәвере пьесаларында үз чорының актуаль һәм мөһим, алдынгы мәсьәләләре күтәрелү. Г.Коләхмәтов пьесаларында әлеге проблемаларның пролетар, марксистик идеология белән үрелеп тасвирлануы, аның драмаларында кеше бәхете, иҗтимагый, социаль гаделлек өчен көрәшүче актив шәхес концепциясенең фәлсәфи, эстетик нигезләре эшләнү, идея-тематик, форма яңалыгы күзәтелү. Г.Исхакыйның ?Алдым-бирдем? (1907), аеруча ?Тартышу? (1908) тарихи-инкыйлаби драмасында яңа тормыш, революцион көрәш өчен үзен корбан иткән татар яшьләре үзәккә куелу. Татар драматургиясенең өченче чорында (1912-1917) иҗат иткән Ф.Әмирхан, Г.Исхакыйларның дөньяга карашларында, әдәби-эстетик эзләнүләрендә яңарышлар, үзгәрешләр. М.Фәйзи (1891-1928), Ш.Камал (1884-1942), Ф.Сәйфи-Казанлы (1888-1937), К.Тинчурин (1887-1947), Ф.Бурнаш (1896-1946) кебек яңа көчләр килү. Тематик яктан, образ-характерлар тудыру алымнарына, конфликт төзелешенә нигезләнеп, чор драматургиясендә берничә юнәлеш ассызыклану. Татар халкының барлык социаль катлаулары берләшеп, милләтнең матди хәлен ныгыту, мәдәниятен, мәгарифен күтәрү өчен барган көрәшне гәүдәләндергән драмалар иҗат ителү. (Ф.Әмирхан ?Тигезсезләр?, 1913). Г.Исхакый ?Мөгаллимә? (1913)).

***лабораторная работа (2 часа(ов)):***

Өченче чорда драма жанрының хәлиткеч роль уйнавы, аның сатирик, психологик, тарихи, романтик, музыкаль драма кебек формалары туу; водевиль, трагикомедия белән жанр ягыннан төрләнүе. 1910-еллар драматургиясенең кеше, аның яшәешен гәүдәләндерү принциплары, алымнары ягыннан катлаулануы. Конфликт оештыру, образ-характерлар тудыру, сәнгатьчә эшләнеш ягыннан драматургиянең җитлегүе.

**Тема 4. Литература 1920-30-х годов (1917-1941) Литература в послевонные годы (1945-1960)**

***лекционное занятие (2 часа(ов)):***

Ил тормышындагы үзгәрешләр. Яңа җәмгыять төзүнең каршылыклары. Яңа хакимиятнең әдәбият-сәнгать өлкәсендәге сәясәте. Бу чорда сүз сәнгатендә төрлелек саклану. Әдәби оешмалар, күмәкләр барлыкка килү. Академик Үзәк төзелү. Татар әдәбиятының үзгәрешләргә мөнәсәбәте. Төп темалар. Әдәби агымнар: символизм, имажинизм, футуризм. Төп көчләр һәм аерым төрләрнең жанрларның үсеше. Яңа система яклаган тәртипләр белән килешмәү. Г.Рәхим, Ф.Әмирхан, М.Фәйзи һ.б. Ф.Әмирханның ?Шәфигулла агай? хикәясендә яңа җәмгыять нигезләрен фаш итү. Сатирик көлү.

***лабораторная работа (2 часа(ов)):***

Г. Ибраһимовның егерменче еллардагы күпкырлы эшчәнлеге. ?Яңа кешеләр? , ?Кызыл чәчәкләр? хикәясендә гаделлек, дусдык мәсьәләләрен алга чыгаруы, әдәбиятның иң матур традицияләренә тугры калуы. Хатын-кыз һәм милләт язмышын үзенчәлекле күренешләрдә, образларда чагылдыру ягыннан ?Казакъ кызы? романы. ?Тирән тамырлар? романында үткән тарих һәм заман вакыйгаларының үзенчәлекле бирелеше.

**Тема 5. Литература в послевонные годы (1945-1960) Литература в 1960-1985-е годы**

***лекционное занятие (4 часа(ов)):***


ЭЛЕКТРОННЫЙ УНИВЕРСИТЕТ ИНФОРМАЦИОННО-АНАЛИТИЧЕСКАЯ СИСТЕМА КФУ

Илдәге сәяси хәл. Сталин үлеме, аның ?шәхес культы?н фаш итү. Репрессияләнгән әдипләрнең аклануы, иҗатлары кайту. М.Җәлил иҗатының киң яңгыраш алуы. Поэзиядә сугыш, җиңү шатлыгы, хезмәт темаларының актуаль булуы. Х.Туфан, Ш.мөдәррис. С.Хәким, Ш.Маннур һ.б. иҗатында кешенең эчке кичерешләрен сурәтләүгә игътибар арту. Мәхәббәт лирикасының активлашуы (Ә.Ерикәй. С.Хәким, М.Ногман, М.Хөсәен һ.б.). Яшь көчләр килү. Эпик поэзиядә сугыш темасының чагылышы (Ш.Маннур, С.Хәким һ.б.). Прозада хәрби-патриотик теманың үстерелеше )Г.Әпсәләмов, М.Әмир, Н.Дәүли һ.б.). Авыл тормышының кырыс хакыйкатен тасвирлау омтылышлары (Ф.Хөсни, Р.Төхфәтуллин һ.б.). Драматургиянең жанр һәм тема төрлелегенә бәйле үсеш-үзгәреш кичерүе. Әдәп-әхлак һәм хезмәт темаларына игътибар арту (Н.Исәнбәт, Ю.Әминев, Г.Насрый һ.б). Әдәбиятның каршылыклы үсеше. ?Конфликтсызлык? теориясе. Г.Бәшировның ?намус? романында сугыш чоры авылы гәүдәләнеше.

***лабораторная работа (4 часа(ов)):***

Әлеге чор әдәбиятының өйрәнелү тарихы. Өстенлек иткән идеологиягә бәйле каршылыклы бәяләнүе. ?Татар әдәбияты тарихы?ның 6 томы басылып чыгу, аның уңышлы һәм бәхәсле яклары. XX гасырның икенче яртысында илдәге тарихи-иҗтимагый вакыйгалар, сәяси хәл, мәдәни тормыш. ?Хрущев җепшеклеге? исеме белән тарихка кереп калган демократик күренешләрнең әдәбият-сәнгатькә уңай йогынтысы. Ил тормышында ?торгынлык? чоры башлану. Милләтләр дуслыгы, интернационализм идеяләре җирлегендә ?совет халкы? формалашу. Рус теленең башка телләрне аралашудан кысрыклап чыгаруы. Татар әдәбиятының ике юнәлештә үсеш-үзгәреше. Соцреализм иҗат методының әдәби-эстетик эчтәлеге киңәю, әдипләрнең еш кына традицион реализмга нигезләнүе. Сурәт чараларының баюы, шартлылык алымнарына, символларга һәм аллегорик образларга актив мөрәҗәгать итү.

**Тема 6. Современная татарская литература (конец XX ? нач.XX1 вв.)**

***лекционное занятие (4 часа(ов)):***

XX гасырның 80 еллары уртасында ил тормышындагы үзгәрешләр. Хәбәрдарлеккә, фикер төрлелегенә юл ачылу. Компартиянең властьтан читләштерелүе. СССР таркалу. Халыкның иҗтимагый активлыгы арту, үзаңы үсеше. Татар халкының мөстәкыйльлек өчен көрәше. Татар телен саклау һәм үстерү, тарихны өйрәнү, әдәби ядкарьләрне кайтару, гореф-гадәтләрне торгызу өчен чаралар күрелү. Үзгәртеп коруларга әдипләрнең мөнәсәбәте. Совет чорында язылган әсәрләргә каршылыклы бәя бирелү. Социалистик реализм иҗат методы турында бәхәсләр. 1980 еллар ахырында сәхнә әдәбиятына килгән авторлар. Татар әдәбиятында сыйфат үзгәрешләре: тематика, жанрлар төрлелеге, сәнгати чаралар байлыгы, иҗат юнәлешләре һәм агымнары.

***лабораторная работа (4 часа(ов)):***

Хәзерге татар поэзиясе, төп көчләре, үзенчәлекләре.Прозада тематик төрлелек, әдипләрнең реалистик, романтик, модернистик алымнарга-чараларга мөрәҗәгать итүе. Сәхнә әдәбиятындагы эзләнүләр. Әйдәп баручы әдипләр иҗатына бәя.

### 4.3 Структура и содержание самостоятельной работы дисциплины (модуля)

| N | Раздел Дисциплины | Семестр | Неделя семестра | Виды самостоятельной работы студентов | Трудоемкость (в часах) | Формы контроля самостоятельной работы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Тема 1. : Иҗтимагый-сәяси атмосфера һәм мәдәни хәл. Әдәби юнәлеш, стиль һәм агымнар төрлелеге. XX гасыр башында татар прозасының яңарышы | 7 | 1-3 | подготовка к контрольной работе | 16 | контрольная работа |

| N | Раздел Дисциплины | Семестр | Неделя семестра | Виды самостоятельной работы студентов | Трудоемкость (в часах) | Формы контроля самостоятельной работы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 2. | Тема 2. XX йөз башы татар шигърияте үсеше: мотивлар һәм жанрлар төрлелеге | 7 | 4-7 | подготовка к тестированию | 14 | тестирование |
| 3. | Тема 3. Милли драматургиянең үсеш баскычлары һәм аларның төп сыйфатлары | 7 | 8-9 | подготовка к коллоквиуму | 13 | коллоквиум |
| 4. | Тема 4. Литература 1920-30-х годов (1917-1941) Литература в послевонные годы (1945-1960) | 7 | 10-11 | подготовка к контрольной работе | 16 | контрольная работа |
| 5. | Тема 5. Литература в послевонные годы (1945-1960) Литература в 1960-1985-е годы | 7 | 12-16 | подготовка к творческому экзамену | 17 | творческое задание |
| 6. | Тема 6. Современная татарская литература (конец XX ? нач.XX1 вв.) | 7 | 17-18 | подготовка к письменной работе | 14 | письменная работа |
| | Итого | | | | 90 | |

## 5. Образовательные технологии, включая интерактивные формы обучения

Рекомендуемые образовательные технологии: лекции, самостоятельная работа студентов, курсовая работа (дисциплина определяется по выбору обучающегося).

При проведении занятий рекомендуется использование активных и интерактивных форм занятий (проблемное обучение, деловые и ролевые игры, анализ конкретных произведений, статей, монографий и т.д., исследовательские технологии, иных форм) в сочетании с внеаудиторной работой. Удельный вес занятий, проводимых в интерактивных формах, должен составлять не менее 30 % аудиторных занятий.

## 6. Оценочные средства для текущего контроля успеваемости, промежуточной аттестации по итогам освоения дисциплины и учебно-методическое обеспечение самостоятельной работы студентов

### Тема 1. : Иҗтимагый-сәяси атмосфера һәм мәдәни хәл. Әдәби юнәлеш, стиль һәм агымнар төрлелеге. XX гасыр башында татар прозасының яңарышы

контрольная работа , примерные вопросы:

I вариант 1. Татар әдәби тәнкыйте барлыкка килү һәм аның татар әдәбиятына йогынтысы. 2. Романтизм юнәлеше, яңа тип (гареб) романтизм формалашу, аның төп сыйфатлары. 3. С.Рәмиевнең ?Яшә, Зөбәйдә, яшим мин? драмасында феминистик (хатын-кыз) мотивлары. II вариант 1. XX гасыр башы татар әдәбияты. Аның яңа күтәрелеше. Өйрәнелү тарихы. 2. Тәнкыйди реализм калыплашу: аның асылы, төп принциплары. 3. К.Тинчуринның ?Соңгы сәлам? драмасында үзәк конфликт, аның үзенчәлеге. III вариант 1. Милли драматургиянең ?театрлы? икенче чоры, төп үсеш тенденцияләре. 2. Романтизм юнәлеше, яңа тип (гареб) романтизм формалашу, аның төп сыйфатлары. 3. Ф.Әмирханның ?Яшьләр? драмасында ?аталар? һәм ?балалар? тартышының гәүдәләнеше. IV вариант 1. Вакытлы матбугат туу һәм аның милли әдәбият үсешенә уңай йогынтысы. 2. Тәнкыйди реализм калыплашу: аның асылы, төп принциплары. 3. Г.Камалның ?Бәхетсез егет? драмасында уку, гыйлем һәм тәрбия мәсьәләләренең хәл ителеше, автор идеалы.

**Тема 2. XX йөз башы татар шигърияте үсеше: мотивлар һәм жанрлар төрлелеге**

тестирование , примерные вопросы:

1. XX йөз башы татар әдәбиятының хронологик чикләре: а) 1901-1917 в) 1895-1917 б) 1905-1918 г) 1908-1917 2. XX йөз башында нәшер ителгән иң озын гомерле газета: а) ?Фикер? в) ?Йолдыз? б) ?Вакыт? г) ?Тормыш? 3. Рәсми рөхсәт белән татар телендә уйналган ?Өч хатын белән тормыш? драмасының вакыты: а) 1906 елның 22 декабре в) 1906 елның 21 апреле б) 1904 елның 4 апреле г) 1906 елның 5 мае 4. Тәнкыйди реализм агымының билгесе: а) кеше яшәешен тасвирлауның рухи принцибы б) типик характерлар типик хәлгә куелу в) кешене яшәеш алдында кечкенә һәм көчсез итеп сурәтләү г) геройның бер сыйфатын гипербола дәрәҗәсенә җиткереп зурайтып сурәтләү 5. Импрессионизм модернистик агымы сыйфатлары калку гәүдәләнгән әдип: а) Н.Думави в) Ш.Камал б) Г.Ибраһимов г) Дәрдемәнд 6. Г.Исхакыйның татар әдәбиятында тәнкыйди реализмның формалашуын хәбәр иткән әсәре: а) ?Ике йөз елдан соң инкыйраз? б) ?Зиндан? в) ?Җәмгыйять? г) ?Зөләйха? 7. Аталар һәм балалар тартышы сурәтләнмәгән әсәр: а) ?Алдым-бирдем? в) ?Яшьләр? б) ?Тигезсезләр? г) ?Ике фикер? 8. Ф.Әмирхан, Г.Исхакый, Г.Камаллар рецензия язган әсәр: а) ?Яшь гомер? в) ?Ачлык кушты? б) ?Хакыйкатьме, хыялмы? г) ?Печән базары яхуд Яңа Кисекбаш? 9. Халыкчылык идеясе гәүдәләнмәгән әсәр: а) ?Мөгаллим? в) ?Алдым-бирдем? б) ?Мөгаллимә? г) ?Теләнче кыз? 10. Милләткә хезмәт итү хакына үз мәхәббәтеннән баш тарткан герой: а) Зөләйха (?Яшь гомер?) б) Рөкыя (?Тигезсезләр?) в) Галия (?Алдым-бирдем?) г) Шакирә (?Тартышу?) д) Фатыйма (?Мөгаллимә?) 11. Г.Тукайның Җаек чоры иҗаты: а) 1895-1905 в) 1905-1907 б) 1895-1907 г) 1905-1906 нчы елларның I яртысы 12. Г.Тукайның халык җырлары калыбына салынмаган әсәре: а) ?Милли моңнар? в) ?Мужик йокысы? б) ?Государственная думага? г) ?Эштән чыгарылган татар кызына? 13. Г.Тукай иҗатының сыйфаты түгел: а) милли в) халыкчылык б) халыкчан г) гыйсъянчылык 14. Реалистик поэзия вәкиле: а) Ш.Бабич в) М.Гафури б) С.Рәмиев г) С.Сүнчәләй 15. Төркиядә белем алган әдип: а) М.Фәйзи в) Дәрдемәнд б) Г.Ибраһимов г) С.Сүнчәләй 16. Сыйнфый көрәш мәсьәләләрен сурәтләмәгән әсәр: а) ?Яшь гомер? в) ?Безнең көннәр? б) ?Тартышу? г) ?Козгыннар оясында? 17. Ш.Камал иҗатында очрамый: а) повесть в)фельетон д) комедия б) хикәя г) новелла е) фаҗига 18. Ш.Камалның ?Козгыннар оясында?гы Садрый кушаматы: а) ?Мыкалкүф? в) ?Җеназа? б) ?Микиш? г) ?Шайтан? 19. Ш.Камал ?Акчарлаклар? повестенда мөрәҗәгать итмәгән агым: а) реализм г) импрессионизм б) натурализм д) экспрессионизм в) романтизм 20. Тукай шигъри мәктәбе вәкиле түгел: а) С.Сүнчәләй в) Дәрдемәнд б) З.Бурнашева г) Ш.Бабич

**Тема 3. Милли драматургиянең үсеш баскычлары һәм аларның төп сыйфатлары**

коллоквиум , примерные вопросы:

1. С. Рәмиев шигъриятендә лирик герой, шәхес бунты, романтик мәхәббәт. Гыйсъянчылык романтизмы. 2.Г. Тукайның Җаек чоры иҗаты: иҗтимагый һәм әдәби ? эстетик карашлары. 3. Дәрдемәнд лирикасы; шигырьләрендә чагылган фәлсәфи уйланулар, сагыш, гамь. Символизм. 4. М.Фәйзинең ?Галиябану? музыкаль пьесасында конфликт һәм характерлар бирелеше. 5.Н. Думави шигърияте.

**Тема 4. Литература 1920-30-х годов (1917-1941) Литература в послевонные годы (1945-1960)**

контрольная работа , примерные вопросы:


ЭЛЕКТРОННЫЙ УНИВЕРСИТЕТ
ИНФОРМАЦИОННО-АНАЛИТИЧЕСКАЯ СИСТЕМА КФУ

Г. Ибраһимовның егерменче еллардагы күпкырлы эшчәнлеге. ?Яңа кешеләр? , ?Кызыл чәчәкләр? хикәясендә гаделлек, дусдык мәсьәләләрен алга чыгаруы, әдәбиятның иң матур традицияләренә тугры калуы. Хатын-кыз һәм милләт язмышын үзенчәлекле күренешләрдә, образларда чагылдыру ягыннан ?Казакъ кызы? романы. ?Тирән тамырлар? романында үткән тарих һәм заман вакыйгаларының үзенчәлекле бирелеше.

**Тема 5. Литература в послевонные годы (1945-1960) Литература в 1960-1985-е годы**

творческое задание , примерные вопросы:

Әлеге чор әдәбиятының өйрәнелү тарихы. Өстенлек иткән идеологиягә бәйле каршылыклы бәяләнүе. ?Татар әдәбияты тарихы?ның 6 томы басылып чыгу, аның уңышлы һәм бәхәсле яклары. XX гасырның икенче яртысында илдәге тарихи-иҗтимагый вакыйгалар, сәяси хәл, мәдәни тормыш. ?Хрущев җепшеклеге? исеме белән тарихка кереп калган демократик күренешләрнең әдәбият-сәнгатькә уңай йогынтысы. Ил тормышында ?торгынлык? чоры башлану. Милләтләр дуслыгы, интернационализм идеяләре җирлегендә ?совет халкы? формалашу. Рус теленең башка телләрне аралашудан кысрыклап чыгаруы. Татар әдәбиятының ике юнәлештә үсеш-үзгәреше. Соцреализм иҗат методының әдәби-эстетик эчтәлеге киңәю, әдипләрнең еш кына традицион реализмга нигезләнүе. Сурәт чараларының баюы, шартлылык алымнарына, символларга һәм аллегорик образларга актив мөрәҗәгать итү.

**Тема 6. Современная татарская литература (конец XX ? нач.XX1 вв.)**

письменная работа , примерные вопросы:

Хәзерге татар поэзиясе, төп көчләре, үзенчәлекләре.Прозада тематик төрлелек, әдипләрнең реалистик, романтик, модернистик алымнарга-чараларга мөрәҗәгать итүе. Сәхнә әдәбиятындагы эзләнүләр. Әйдәп баручы әдипләр иҗатына бәя.

**Тема . Итоговая форма контроля**

Примерные вопросы к экзамену:

Экзамен билетлары:

1. Г.Исхакый иҗатының "таңчы"лык дәвере: иҗтимагый-сәяси карашларында һәм сәнгатьчә фикерләвендәге үзгәрешләр. "Алдым-бирдем" драмасында күтәрелгән мәсьәләләр, конфликт бирелеше.

2. Н.Думави шигърияте ("Берлек-иттифак", "Революция заманы", "Эч поша, күңел болгана", "Мәңгелек мәхбүс", "Бизмә дөньядан", "Беренче кар", "Мәхәббәт", "Сугыш", "Сугыш тәэссораты" һ.б.). Экспрессионизм.

3. 1905-1907 еллар инкыйлабы нәтиҗәсе буларак татар вакытлы матбугаты

барлыкка килү һәм аның әдәбият үсеше өчен әһәмияте.

4. Г.Исхакыйның тормыш юлы, иҗтимагый-сәяси, журналистлык эшчәнлеге.

5. Г.Камал - комедия остасы, пьесаларында көлү, фаш итү объектлары. "Банкрот", "Бүләк өчен" комедияләре.

6. Г.Тукайның Җаек чоры иҗаты: иҗтимагый һәм әдәби-эстетик карашлары ("Мужик йокысы", "Дустларга бер сүз", "Хөррият хакында", "Государственная думага", "Алтынга каршы", "Сорыкортларга", "Китмибез", "Шүрәле", "Милләткә", "Үз-үземә" һ.б.).

7. Татар әдәбиятында тәнкыйди реализмның формалашуы. Аның асылы, иҗат методы буларак принциплары, тарихи традицияләре.

8. Г.Ибраһимовның "Карт ялчы", "Уты сүнгән җәһәннәм" хикәяләрендә кеше бәхете, яшәү мәгънәсе турында уйланулар, бу мәсьәләгә автор мөнәсәбәте.

9. Татар драматургиясенең өченче дәвере (1912-1917). К.Тинчуринның 10 нчы еллардагы әдәби эшчәнлеге. "Соңгы сәлам" мелодрамасы.

10. Г.Ибраһимовның икенче чор (1912-1917) иҗатындагы сыйфат үзгәрешләре. Язучының әдәби-эстетик, фәлсәфи карашлары. "Табигать балалары", "Мәрхүмнең дәфтәреннән" хикәяләре.

11. Г.Ибраһимовның "Яшь йөрәкләр" романында романтик шәхесләр, иске татар тормышының гәүдәләнеше, кеше һәм сәнгать мөнәсәбәте.

12. XX йөз башы татар матур әдәбиятында "кечкенә кеше" темасының гәүдәләнеше (Г.Исхакый, Ш.Камал, М.Гафури һ.б.).

13. Г.Тукайның 1908-1910 еллар лирикасында идея-эстетик үзгәрешләр. Романтик сурәтләү алымнарының, чараларының чагылышы ("Өмидсезлек", "Җәйге таң хатирәсе", "Милли моңнар", "Мәхәббәт", "Шагыйрь", "Пәйгамбәр" һ.б.).

14. Ш.Бабичның тормыш юлы һәм күпкырлы эшчәнлеге. Лирикасының төп сыйфатлары ("Бәхетем", "Шатлык җыры", "Халкым өчен", "Бәнем фәрештәм", "Скрипка", "Бер минут", "Тын төн", "Габдулла әфәнде Тукаев", "Ике аккош", "Утрау" һ.б.). "Газазил поэмасы".

15. XX йөз башы татар әдәбиятында сатира, аның җирлеге. Милли әдәбиятта сатираны үткенәйтүче алымнар. Әдипләр иҗатыннан мисаллар белән расларга.

16. Г.Исхакыйның 10-еллар иҗаты. "Ул әле өйләнмәгән иде" повесте.

17. Ш.Камал иҗаты. Кеше тормышын, аның күңел дөньясын сурәтләү үзенчәлекләре. Импрессионизм. ("Уяну", "Буранда", "Сулган гөл").

18. Г.Тукай сатирасы. Аның көлү, фаш итү объектлары, алымнары ("Сорыкортларга", "Пыяла баш", "Печән базары яхуд Яңа Кисекбаш", "Милләтчеләр" һ.б.).

19. Г.Камалның драмалары. Конфликт бирелеше һәм күтәрелгән мәсьәләләр ("Бәхетсез егет", "Уйнаш").

20. Г.Тукайның 10 нчы еллар лирикасындагы мотивлар ("Хөрмәтле Хөсәен ядкәре", "Читен хәл", "Кыйтга", "Хәстә хәле", "Сайфия", "Олуг юбилей мөнәсәбәте..." һ.б.).

21. Дәрдемәнд лирикасы; шигырьләрендә чагылган фәлсәфи уйланулар, сагыш, гамь. Символизм. Бер-ике шигырен яттан сөйләргә.

22. XX йөз башы татар прозасында тарихи теманың гәүдәләнеше. (Ф.Әмирхан, Г.Исхакый, Н.Думави, Ш.Әхмәдиев һ.б.). "Сөенбикә", "Хан кызы Алтынчәч" һ.б.

23. Ш.Әхмәдиев иҗаты: тематик киңлек һәм жанр төрлелеге. "Мөгаллим", "Кеше", "Шагыйрь моңая", "Суга баткан килен" һ.б.

24. Г.Тукай иҗаты. Аны чорларга бүлү мәсьәләсе. Шагыйрь иҗатының төп үзенчәлекләре. Бер-ике шигырен яттан сөйләргә.

25. М.Гафури прозасында гади халык язмышының сурәтләнеше, әсәрләренең сәнгатьчә эшләнеше ("Ярлылар яки өйдәш хатын"). Натурализм.

26. Ф.Әмирханның хикәяләре, романтик эстетика сыйфатларының чагылышы ("Кадерле минутлар", "Яз исереклегендә").

27. С.Рәмиевнең проза һәм драма төрләрендә эшчәнлеге. "Яшә, Зөбәйдә, яшим мин" әсәрендә феминистик (хатын-кыз) мәсьәләләрнең чагылышы.

28. Г.Газиз (Гобәйдуллин Г.) хикәяләре: "Моң", "Яшьләр кичәсе", "Скрипкачы Хөсәен", "Чалбар" һ.б.

29. Ф.Әмирханның "Яшьләр" драмасында күтәрелгән мәсьәләләр һәм аларның сәнгатьчә хәл ителеше.

30. Г.Коләхмәтов драматургиясе. Бу төргә ул алып килгән яңа сыйфатлар. "Яшь гомер" драмасының идея эчтәлеге, пролетар әдәбият билгеләренең чагылышы.

31. Ф.Әмирхан иҗатында хатын-кыз темасы. Әдипнең "Хәят" повесте. Яшь кеше кичерешләрен сурәтләүдә әдипнең осталыгы. Әсәрнең иҗат ысулы мәсьәләсе.

32. С.Җәләлнең "Дим буенда" повесте. Мәхәббәт темасының сурәтләнеше.

33. Г.Исхакыйның өченче чор иҗаты. "Остазбикә" әсәренең идея-эстетик үзенчәлекләре.

34. Г.Исхакыйның "Зөләйха" трагедиясе. Жанр үзенчәлеге. Пьесада әдип мөрәҗәгать иткән алымнар һәм чаралар.

35. С.Рәмиев шигъриятендә лирик герой, шәхес бунты, романтик мәхәббәт. Гыйсъянчылык романтизмы ("Таң вакыты", "Мин", "Син", "Ул", "Алданган", "Дөньяга", "Авыл" һ.б.). Бер шигырен яттан сөйләргә.

36. XX йөз башы татар әдәбияты. Өйрәнелү тарихы. Чор үзенчәлеге. Сүз сәнгате үсешенең яңа күтәрелеше.

37. Татар әдәби тәнкыйтенең формалашуы, бурычлары. (Г.Ибраһимов, Ф.Әмирхан, Г.Тукай, Җ.Вәлиди һ.б.).


ЭЛЕКТРОННЫЙ УНИВЕРСИТЕТ
ИНФОРМАЦИОННО-АНАЛИТИЧЕСКАЯ СИСТЕМА КФУ

38. Милли драматургиянең икенче баскычы (1906-1911). Татар профессиональ театры формалашу һәм аның драматургия үсешенә уңай йогынтысы.

39. Г.Камалның күпкырлы эшчәнлеге. Әдипнең башлангыч чор иҗаты ("Өч бәдбәхет", "Кызганыч бала" һ.б.).

40. Ш.Камалның "Козгыннар оясында", "Сукбай", "Бәхет эзләгәндә" хикәяләрендә бәхет мәсьәләсе, конфликт үзенчәлеге.

41. Ф.Әмирханның "Тигезсезләр" драмасында татар яшьләренең рухи, фикри, үсеш баскычларын сурәтләү. Пьесаның сәнгатьчә эшләнеше.

42. Ф.Әмирханның "Бер хәрабәдә", "Сүнгәч", "Татар кызы" хикәяләре. Модернистик агымнарның сыйфатлары.

43. Ф.Әмирханның сатирасында көлү, тәнкыйтьләү объектлары, сурәтләү алымнары ("Фәтхулла хәзрәт" һ.б.).

44. Г.Рәхим хикәяләренең идея-эстетик үзенчәлекләре: "Галия", "Көзге хикәя", "Миләүшәләр арасында", "Хан мәчетендә", "Артист".

45. Н.Думави хикәяләре: идея-эстетик үзенчәлекләре (реалистик, романтик, модернистик катламнарның чагылышы). "Кем гаепле", "Мортый илә Мукай", "Су кызы", "Карт мөгаллимнәр" һ.б.

46. Ш.Камалның "Акчарлаклар" әсәре: идея-проблематикасы һәм сәнгати үзенчәлекләре. Кешенең эчке һәм тышкы матурлыгына дан җырлау.

47. М.Гафуриның шигърияте. Шагыйрь иҗатында шәхес иреге, социаль азатлык турында уйланулар; гомумкешелек кыйммәтләре белән сыйнфый мәнфәгатьләр арасында мөнәсәбәтнең чагылышы.

48. Г.Исхакыйның "Зиндан" повесте. Жанр үзенчәлеге, күтәрелгән мәсьәләләр, әсәрнең автобиографик җирлеге.

49. Г.Исхакыйның "Тормышмы бу?" әсәрендә иске татар тормышы, мәктәп-мәдрәсәләрнең сурәтләнеше. Мәхдүм образының бирелеше.

50. М.Фәйзинең драматургиясе. "Яшьләр алдатмыйлар" "Кызганыч" пьесаларының идея-проблематикасы һәм сәнгатьчә эшләнеше.

51. Г.Исхакыйның башлангыч чор иҗаты. Бу этапның төп сыйфатлары. "Ике йөз елдан соң инкыйраз" повесте. Аның идея-проблематикасы, жанры, әсәрнең татар әдипләре иҗатына йогынтысы.

52. Татар әдәбиятында романтизмның әдәби агым буларак формалашуы, сәбәпләре, милли әдәбиятка романтизм алып килгән сыйфатлар.

### 7.1. Основная литература:

Галиуллин Т.Н. Әдәбият - хәтер хәзинәсе: укытучылар, педагогика колледжлары һәм югары уку йортлары студентлары өчен кулланма. Казан: Мәгариф, 2008. 231 б.

Закирҗанов Ә. Заман белән бергә. - Казан:Тат.кит.нәшр., 2004. - 175 б.

Закирҗанов Ә.М. Яңарыш юлыннан (хәзерге татар әдәбият белеме мәсьәләләре): монография / Фәнни мөхәррире Р.К.Ганиева. Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. 303 б.

Заһидуллина Д. Яңа дулкында (1980-2000 еллар татар прозасында традицияләр һәм яңачалык). - Казан: Мәгариф, 2006. - 255 б.

Татар әдәбияты: Теория. Тарих / Д.Ф.Заһидуллина, Ә.М.Закирҗанов, Т.Ш.Гыйләҗев, Н.М.Йосыпова. - Тулыл. 2 нче басма.- Казан: Мәгариф, 2006. - 319 б.

Хәзерге татар әдәбияты.- Казан: Мәгариф, 2008.- 455 б.

### 7.2. Дополнительная литература:

Аминева В.Р. Типы диалогических отношений между национальными литературами (на материале произведенй русских писателей второй половины XIX в. и татарских прозаиков первой трети XX в. Казань: Казан. гос. ун-т, 2010. 476 с.



ЭЛЕКТРОННЫЙ УНИВЕРСИТЕТ
ИНФОРМАЦИОННО-АНАЛИТИЧЕСКАЯ СИСТЕМА КФУ

Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге / фәнни мөх. Т.Галиуллин, Д.Заһидуллина. - Казан: Мәгариф, 2007. - 231 б.

Әхмәдуллин А.Г. Офыклар киңәйгәндә. Казан: Татар. кит. нәшр., 2003.

Әхмәдуллин А. Күңелләрне уятыр: Хәзерге татар драматургиясе. - Казан: Мәгариф, 2007. - 223 б.

Галимуллин Ф.Г. Офыкларны алдан күреп. - Казан: Тат.кит.нәшр., 1995.- 200 б.

Галиуллин Т.Н. Шагыйрьләр һәм шигырьләр. - Казан: Тат.кит.нәшр., 1985.- 208 б.

Галиуллин Т.Н. Шигърият баскычлары. - Казан: Мәгариф, 2002.- 231 б.

Галиуллин Т.Н. Шәхесне гасырлар тудыра. - Казан: Тат.кит.нәшр., 2003.- 192 б.

Закирзянов А.М. Основные направления развития современного татарского литературоведения (кон. XX - нач. XXI вв.). - Казань: Ихлас, 2011. - 320 с.

Миңнуллин Ф.М. Балта явызлар кулында. - Казан: Тат.кит.нәшр., 1994.- 344 б.

Мусин Ф. М. Чор белән аваздаш. - Казан: Тат.кит.нәшр., 1983. - 298 б.

Сверигин Р. Яңа герой һәм яңа алымнар. - Казан: Тат.кит.нәшр., 1985. - 156 б.

Татар әдәбияты тарихы. 6 томда. 4 том.- Казан: Тат.кит.нәшр., 1989.-567 б.

Татар әдәбияты тарихы. 6 томда. 5 том. - Казан: Тат.кит.нәшр., 1989.-543 б.

Татар әдәбияты тарихы. Алты томда. Т.6. -Казан: Раннур, 2001.- 544 б.

Фәттахов И. Жанр нечкәлекләрен ачыклаучы хезмәт (Әнүр Исхак улы Исмәгыйлевнең "Сәнгать һәм жанр" монографиясенә рецензия) // Мәдәни җомга. 2011. 30 дек. � 52 (853).

Хатипов Ф.М. Мөлкәтебезне барлаганда. - Казан: Тат.кит.нәшр., 2003. - 272 б.

Халит Г.М. Кешегә һәм чынлыкка мәхәббәт белән. - Казан: Тат.кит.нәшр., 1979.- 287 б.

Яхин А.Г. 10 сыйныфта татар әдәбиятын укыту. Укытучылар өчен методик кулланма. - Казан: Мәгариф,1995.- 143 б

Юзеев Н.Г. Шигърият дөньясы. - Казан: Тат.кит.нәшр., 1981. - 312 б.

### 7.3. Интернет-ресурсы:

КНИГОФОНД - KNIGAFUND

КФУ - Научная библиотека им. Н.И.Лобачевского - old.kpfu.ru/lib/

Научная библиотека им. Н.И.Лобачевского Казанского ... - g-egorov.livejournal.com/115591.html

Научная библиотека им.Лобачевского Казанского университета - lsl.ksu.ru

Научно-образовательные ресурсы КФУ - http://www.kpfu.ru/main_page?p_sub=80

Электронная Библиотека КГУ / Каталог Книг - library.ksu.ru

### 8. Материально-техническое обеспечение дисциплины(модуля)

Освоение дисциплины "История татарской литературы XX века" предполагает использование следующего материально-технического обеспечения:

Компьютерный класс, представляющий собой рабочее место преподавателя и не менее 15 рабочих мест студентов, включающих компьютерный стол, стул, персональный компьютер, лицензионное программное обеспечение. Каждый компьютер имеет широкополосный доступ в сеть Интернет. Все компьютеры подключены к корпоративной компьютерной сети КФУ и находятся в едином домене.


ЭЛЕКТРОННЫЙ УНИВЕРСИТЕТ
ИНФОРМАЦИОННО-АНАЛИТИЧЕСКАЯ СИСТЕМА КФУ

Учебно-методическая литература для данной дисциплины имеется в наличии в электронно-библиотечной системе " БиблиоРоссика", доступ к которой предоставлен студентам. В ЭБС " БиблиоРоссика " представлены коллекции актуальной научной и учебной литературы по гуманитарным наукам, включающие в себя публикации ведущих российских издательств гуманитарной литературы, издания на английском языке ведущих американских и европейских издательств, а также редкие и малотиражные издания российских региональных вузов. ЭБС "БиблиоРоссика" обеспечивает широкий законный доступ к необходимым для образовательного процесса изданиям с использованием инновационных технологий и соответствует всем требованиям федеральных государственных образовательных стандартов высшего профессионального образования (ФГОС ВПО) нового поколения.

Учебно-методическая литература для данной дисциплины имеется в наличии в электронно-библиотечной системе "ZNANIUM.COM", доступ к которой предоставлен студентам. ЭБС "ZNANIUM.COM" содержит произведения крупнейших российских учёных, руководителей государственных органов, преподавателей ведущих вузов страны, высококвалифицированных специалистов в различных сферах бизнеса. Фонд библиотеки сформирован с учетом всех изменений образовательных стандартов и включает учебники, учебные пособия, УМК, монографии, авторефераты, диссертации, энциклопедии, словари и справочники, законодательно-нормативные документы, специальные периодические издания и издания, выпускаемые издательствами вузов. В настоящее время ЭБС ZNANIUM.COM соответствует всем требованиям федеральных государственных образовательных стандартов высшего профессионального образования (ФГОС ВПО) нового поколения.

Учебно-методическая литература для данной дисциплины имеется в наличии в электронно-библиотечной системе Издательства "Лань" , доступ к которой предоставлен студентам. ЭБС Издательства "Лань" включает в себя электронные версии книг издательства "Лань" и других ведущих издательств учебной литературы, а также электронные версии периодических изданий по естественным, техническим и гуманитарным наукам. ЭБС Издательства "Лань" обеспечивает доступ к научной, учебной литературе и научным периодическим изданиям по максимальному количеству профильных направлений с соблюдением всех авторских и смежных прав.

Компьютерный класс, оргтехника, теле- и аудиоаппаратура (всё - в стандартной комплектации для лабораторных занятий и самостоятельной работы); доступ к сети Интернет (во время самостоятельной подготовки и на лабораторных занятиях).

Программа составлена в соответствии с требованиями ФГОС ВПО и учебным планом по направлению 031300.62 "Журналистика" и профилю подготовки Средства массовой информации (национальная журналистика) .



ЭЛЕКТРОННЫЙ УНИВЕРСИТЕТ
ИНФОРМАЦИОННО-АНАЛИТИЧЕСКАЯ СИСТЕМА КФУ

Автор(ы):
Фаттахов И.Ф. ____________________
"__" _________ 201 __ г.

Рецензент(ы):
Гарифуллин В.З. ____________________
Зайни Р.Л. ____________________
"__" _________ 201 __ г.